*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 36**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. [w] авазы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
 а) су
 ә) автор
 б) савыт
 в) ваза

2. Җөмләдәге ачык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
 *Колагыңа ышанма, үзеңә ышан*. (Мәкаль).
 а) 2
 ә) 5
 б) 8
 в) 10

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
 *Кул арасына керү*
 а) комачаулау
 ә) булышу
 б) зур үсү
 в) йоклау

4. Омонимнарны билгеләгез. **(2 балл)**
 а) картаю – карт аю
 ә) матур – чибәр
 б) ак – кара
 в) алтын кул – алтын алка

5. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
 а) чүл, чүлмәк
 ә) как, ак
 б) күз, сүз
 в) тиш, тишек

6. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) без
ә) сез
б) шул
в) мин

7. Киләчәк заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) укы
ә) укыячак
б) укыган
в) укый

8. Җәенке җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Көз җитте.
ә) Яңгыр ява.
б) Үги ана яфрагы үсә.
в) Сары яфраклар коела.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган хәрефне һәм сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

ъ, ь һәм _____ хәрефләре баш хәрефтән язылмыйлар. Татар телендә тартык авазлар яңгырау һәм _____________ була. Капма-каршы мәгънәле сүзләр ________________ дип атала. _____________ – тамырга ялганып килә торган кисәк. Предметның төгәл исәбен, санын ____________ саны белдерә.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(9 балл)**

*Был в лесу старый пень. Тут в дупле ёж сделал гнездо. В гнездо он натаскал травы. Стало тепло и мягко. Днём ёж спал. А вечером выходил на охоту.*

2. Урман хайваннары кышка ничек әзерләнә? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**